**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Верхнешипкинского**
**сельского поселения Заинского**
**муниципального района**

Ул. Молодежная , д. 1, с. Верхние Шипки,
Заинский район, 423518

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Югары Шепкә авыл**
**җирлегенең башкарма**
**комитеты**

Яшьләр урамы, 1нче йорт, Югары
Шепкә авылы, Зәй районы, 423518

Телефон, факс 69-2-77. Электронный адрес: Vship.Zai@tatar.ru, сайт:
www.zainsk.tatarstan.ru/tat/verhneshipkinskoe.htm

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30 июль 2019ел** **№ 11**

**«Сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында»**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2019 нчы елның 10 нчы июлендәге 67/516 номерлы «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» карары, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә

**карар бирәм:**

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районыЮгары Шепкә авыл җирлеге сайлау участоклары территориясендә махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазландырырга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең сайлау участоклары территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен урыннар исемлеген расларга (Кушымта).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карарны Зәй муниципаль районы сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә Югары Шепкә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе А.Х.Ишмәтов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Югары Шепкә авыл җирлеге
Башкарма комитет карарына
Кушымта
30июль 2019№ 11

**Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең сайлау участоклары территориясендә урыннар исемлеге**

| № п/п | Сайлау участогы № | Объектның исеме һәм урнашу адресы |
|---|---|---|
| 1. | 1469 | Мәгълүмат стенды<br>Югары Шепкә авылы, Яшьләр урамы, 1А йорт |
| 2. | 1469 | Мәгълүмат стенды<br>Югары Шепкә авылы, Үзәк урам 52 йорт |
| 3. | 1470 | Мәгълүмат стенды<br>Имәнлебаш  авылы, Үзәк урам |
| 4. | 1470 | Мәгълүмат стенды<br>Иске Пәлчекәү авылы, Үзәк урам |
| 5. | 1470 | Мәгълүмат стенды<br>Бәләкәй Пәлчекәү авылы, Үзәк урам |